ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 22 ноябре** Күгәй авылы **№ 14**

Зеленодольск муниципаль районының Күгей авыл җирлеге башкарма комитетының 01.09.2023 елгы №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгей авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә Зеленодольск муниципаль районы Күгей авыл җирлеге Башкарма комитетының 01.09.2023 ел no 19 карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.

1.2. 5 пунктның «б " пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү;

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

**Күгәй авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Х.Хисаметдинова**